МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.05.2018 № 283

**Казан ш.**

Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең
һәм багаж ташуның муниципальара
маршруты буенча пассажирлар йөртүне
һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында
таныклык һәм тиешле маршрутлар карталары
ачык конкурс үткәрелмичә генә бирелә торган
юридик затны, индивидуаль эшкуарны,
гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыны
билгеләү тәртибен раслау турында

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законны һәм “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары ачык конкурс үткәрмичә генә бирелә торган юридик затны, индивидуаль эшкуарны, гади ширкәт шартнамәсендә

катнашучыны билгеләү тәртибен расларга.

2. Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлеге башлыгы Н.Н.Доброхотов әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә тиеш.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Транспорт идарәсе башлыгы А.В. Сидоровка йөкләргә.

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының 2018 елның 10 маендагы
283 номерлы боерыгы белән расланды

Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрутлар карталары ачык конкурс үткәрелмичә генә бирелә торган юридик затны, индивидуаль эшкуарны, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыны билгеләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык (алга таба – (туры килү буенча) таныклык, маршрут) һәм тиешле маршрутлар карталары (алга таба – маршрут карталары) ачык конкурс үткәрелмичә генә бирелә торган юридик затны, индивидуаль эшкуарны, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыны (алга таба – гариза бирүче) билгеләү процедурасын билгели.

2. Ачык конкурс үткәрмичә генә маршрут таныклыклары һәм маршрут карталары бирү

3. Таныклык һәм маршрут карталары ачык конкурс үткәрмичә генә “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 19 статьясында каралган очракларда, срокта һәм чорга бирелә.

4. Федераль законның 19 статьясындагы 3 өлешендә каралган хәлләр барлыкка килгән очракта, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) әлеге хәлләр барлыкка килгән көнне “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында “Эшчәнлек” бүлегенең “Ачык конкурс үткәрмичә генә маршрут таныклыклары һәм маршрут карталары бирү тәкъдимнәре” бүлекчәсендә (алга таба – “Интернет” челтәре) ачык конкурс үткәрмичә генә маршрут таныклыклары һәм маршрут карталары бирү турында тәкъдимнәр (алга таба – тәкъдимнәр) урнаштыра.

5. Тәкъдимдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) маршрутның исеме;

2) маршрутның озынлыгы;

3) әлеге маршрут буенча пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өчен таләп ителә торган һәм кимендә сигез кешене йөртү өчен җиһазландырылган автомобиль транспортында пассажирлар йөртү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга лицензиядә күрсәтелгән эш төре (алга таба – лицензия);

4) автобусларның маршрут буенча хәрәкәт итү расписаниесе;

5) транспорт чарасының төре, классы, экологик классы (алга таба – транспорт чарасы) турында, шулай ук маршрутка хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган транспорт чарасының саны турында белешмәләр.

6. Таныклык һәм карталар алу белән кызыксынучы гариза бирүче, “Интернет” челтәрендә тәкъдим чыккан көннән соңга калмыйча, таныклык һәм маршрут карталары алу өчен 420061, Николай Ершов урамы, 31а йорт адресы буенча Министрлыкка мөрәҗәгать итә, түбәндәге документларны тапшыра:

1) лицензия күчермәсен:

- муниципальара маршрутның озынлыгы 50 км га кадәр булган очракта, эш төренә - шәһәр һәм шәһәр яны маршрутларында даими рәвештә пассажирлар йөртүгә лицензиянең күчермәсе тапшырыла;

- муниципальара маршрутның озынлыгы 50 км дан артыграк булган очракта, эш төренә - шәһәрара маршрутларда даими рәвештә пассажирлар йөртүгә лицензиянең күчермәсе тапшырыла;

2) әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә транспорт чаралары исемлеге, тәкъдимдә күрсәтелгән таләпләргә һәм саннарга туры килә торган транспорт чараларын милек хокукында һәм (яисә) законнарда каралган башка хокукта биләүне раслый торган документларның күчермәләре, транспорт чаралары паспортларының, аларны теркәү таныклыкларының күчермәләре кушымта итеп бирелә;

3) гади ширкәт шартнамәсенең күчермәсе һәм вәкаләтләрне раслый торган документ (гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар өчен).

Документлар күчермәләренең һәр бите гариза бирүче зат җитәкчесе яисә гариза бирүче исеменнән эш итәргә вәкаләтле башка зат йә гариза бирүче затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан, ышанычнамә кәгазен кушымта итеп биреп, имзаланырга тиеш.

Гади ширкәт шартнамәсендә катнашучының вәкаләтле вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, документларны күчермәсе гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларны һәрберсе тарафыннан имзалана. Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән документлар гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның һәрберсенә карата бирелә.

7. Беренче мөрәҗәгать иткән һәм әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган гариза бирүчегә маршрут таныклыгы һәм карталары бирелә.

8. Министрлык маршрут таныклыгы һәм карталары бирелгән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча “Интернет” челтәрендә әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә мәгълүмат урнаштыра.

9. Әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яисә тулысынча тапшырмау маршрут таныклыгын һәм карталарын бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Җайга салынмый торган тарифлар
буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең
һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча
пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә
ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрутлар
карталары ачык конкурс үткәрелмичә генә бирелү тәртибенә
1 нче кушымта

**Транспорт чаралары булу һәм аларның характеристикалары турында белешмәләр ____ ат көче:**

| Т/с | ТЧ маркасы/ төре | ТЧ дәүләт номеры | Транспорт чараларының йөртүчеләрнең хәрәкәт, хезмәт һәм ял режимын үтәүләрен тикшереп тору өчен техник чаралар (тахограф) һәм спутник навигациясе аппаратурасы ГЛОНАС яисә ГЛОНАСС/GPS белән җиһазланган булуы, һәр берәмлеккә исәпләгәндә. | ТЧ төре | Эшләнгән елы | ТЧ озынлыгы | Двигатель төре (экологик классы) | Кондиционер, коляскада йөрүче инвалидлар һәм балалы пассажирлар өчен җайланмалар булу |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

Ачык конкурста катнашучының җитәкчесе/
вәкаләтле заты ________________________ ( ____________________ )
*(Ф.ИАт ис.)*

буенча д
һәм багаж ташун
пассажирлар
ашыру турынд
карталары ачык конкур

| **Җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрутлар к генә бирелгән гариза бирүчеләр турында мәгълүмат** | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Даими ташулар маршрутының теркәү номеры | Даими ташулар маршрутының тәртип саны | Даими ташулар маршрутының исеме | Даими ташулар маршрутында тукталыш пунктлары исеме | Даими ташулар маршрутында тукталыш пунктлары арасындагы урамнар, автомобиль юллары исеме | Даими ташулар маршрутының озынлыгы, км | Лицензия | Пассажирларны утырту-төшерү тәртибе | Даими ташулар төре | Файдаланыла торган ТЧ төрләре һәм классы | | | Т эк г кл |
| | | | | | | | | | Төр | Класс | Һәр класслы ТЧ максималь саны | |